| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**29.09.2015** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2007** |

2015-2016 елларның Зеленодольск муниципаль районы территориясендә «Ягып җылыту» янгын-профилактика операциясен үткәрү һәм көзге-кышкы янгын куркынычы чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү турында

1994 елның 21 декабрендәге «Янгын куркынычсызлыгы турында» 69-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 06 октябрендәге«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 123-ФЗ номерлы Федераль закон, һәм Россия Федерациясе Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ЗМР буенча Баш идарәсе башлыгының 2015 елның 09 сентябрендәге 841-2-24-24 номерлы «Ягып җылыту» янгынга каршы көрәш операциясен уздыру турында» 841-24-24 номерлы хаты нигезендә, Зеленодольск муниципаль районында 2015-2016 елгы көзге-кышкы янгын куркынычы чорында янгынга каршы режимны тәэмин итү максатларында,Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә 2015-2016 елның көзге-кышкы янгын куркынычы чорында «Ягып җылыту» янгын-профилактика операциясен оештырырга һәм уздырырга.
2. 2015-2016 елның көзге-кышкы янгын куркынычы чорында Зеленодольск муниципаль районы объектларын әзерләү һәм аларның эшен оештыру планын расларга (кушымта).
3. Шәһәр тибындагы поселокларның һәм авыл җирлекләренең башкарма комитетлары башлыкларына һәм җитәкчеләренә, предприятие, оешма һәм учреждениеләр җитәкчеләренә 2015-2016 елның көзге-кышкы янгын куркынычы чорында объектлар әзерләүне һәм аларның эшен план нигезендә оештырырга тәкъдим итәргә.
4. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы А.Н. Коршуновка әлеге карарны җирле массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче С.Г.Егоров

ЗМР Башкарма комитеты карарына кушымта
« 29 » _09_2015 ел №2007

ПЛАН
2015-2016 елның көзге-кышкы янгын куркынычы чорында Зеленодольск муниципаль районы объектларын әзерләү һәм аларның эшен оештыру.

| № т/б | Чаралар | Үтәү вакыты | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1. | Предприятиеләрнең, оешмаларның һәм учреждениеләрнең янгынга каршы торышына тикшерүләр үткәрү буенча комиссияләр төзү. Тикшерү нәтиҗәләре буенча материаллар, җаваплы затларны һәм башкару срокларын күрсәтеп, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозуларны бетерү буенча чаралар планнарын карарга һәм аларны төзергә. | 10.10.2015 | Оешмалар, предприятиеләр җитәкчеләре, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә |
| 2. | Янгынны сүндерүнең беренчел чараларын, янгын турында хәбәр итү һәм сүндерү автомат җайланмаларын, авария хәлендәге һәм эвакуация яктырту системаларын, янгын турында хәбәр итү системаларын, эш хәлендә эвакуацияләүнең төп һәм запас юлларын карап тотуны тикшерү. | 10.10.2015 | Милеккә бәйсез рәвештә, оешмалар, предприятиеләр җитәкчеләре |
| 3. | Техниканы янгын сүндерү максатларында төзек хәлгә китерү һәм аны даими әзерлектә тоту. | Даими | Җирлек башлыклары, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, предприятие, оешма җитәкчеләре |
| 4. | Янгынга каршы су белән тәэмин итү челтәрләренә һәм чыганакларына көзге хезмәт күрсәтү буенча кирәкле эшләр башкару. Күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенә һәм «Татарстан Республикасы буенча 8 ОФПС» ФДБФнә челтәрләргә һәм янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларына көзге хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча белешмәләр тапшыру | 30.10.2015 | Җирлек башлыклары, предприятие, оешма җитәкчеләре, баланс тотучылар |
| 5. | Электр челтәрләренең, җылылык җитештерүче агрегатларның, электр агрегатларының һәм башка электр приборларының һәм электр җайланмаларының торышының төзеклеген тикшерү. | 10.10.2015 | Милеккә бәйсез рәвештә, оешмалар, предприятиеләр җитәкчеләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. | Ягулык-энергетика комплексы объектларының һәм торак пунктларның яңа җылылык сезоны башлануга әзерлеген тикшерү | 10.10.2015 | Җирлек башлыклары, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, оешмалар, предприятиеләр җитәкчеләре |
| 7. | Хезмәт, җитештерү, склад, чардак һәм подвал бүлмәләрендә ,шулай ук Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы территорияләре һәм урамнарында чүп-чар һәм яна торган җитештерү калдыкларын җыештыру, Предприятиеләр һәм торак секторлары территорияләрендә чүп-чар яндыруны тыярга. Торак йортларның подвал һәм чердаклы биналарына керү мөмкинлеген төшереп калдырырга. | 10.10.2015 | Җирлек башлыклары, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, предприятие, оешма җитәкчеләре |
| 8. | Торак пунктларның (авыл җирлекләренең) һәм оешмаларның тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларын, тышкы янгын баскычларын, биналарга һәм корылмаларга керү юлларын тиз арада урнаштыру өчен тәүлекнең караңгы вакытында яктыртуны тәэмин итү | 10.10.2015 | Җирлек башлыклары, җитәкчеләр милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, предприятиеләр, оешмалар |
| 9. | Янгын сүндерү өчен һәм техниканы янгын сүндерү максатларында җайлаштырылган ягулык-майлау материаллары резервын булдыру | 10.10.2015 | Җирлек башлыклары, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, предприятие, оешма җитәкчеләре |
| 10. | Аз керемле гражданнарга мичтә җылыту һәм электр үткәргечләрен ремонтлау буенча социаль ярдәм күрсәтү. Халыкның социаль якланмаган катламнарына адреслы ярдәм күрсәтү, шул исәптән әлеге категориядәге гражданнар яшәгән урыннарда автоном янгын сүндерү хәбәрчеләре урнаштыру. | Даими | АҖ башлыклары, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмалар, предприятиеләр җитәкчеләре |
| 11. | Кышын кар һәм боздан янгын гидрантларын, торак пунктларга, подъездларга һәм объектларга, торак йортларга һәм янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итү чыганакларына юлларны вакытында чистарту, янгын гидрантларын, су башняларын җылыту, аларның координаталы күрсәткечләрен яңарту эшләрен оештыру. Әлеге эшләрне башкарганда шәхси төзелеш өстенлек итүче Зеленодольск шәһәре торак пунктларына һәм районнарына аерым игътибар бирергә. | Даими | АҖ башлыклары, ЗМР ТКХ департаменты, "Жилкомплекс" ИК, идарәче компанияләр, "Коммуналь хуҗалык" МУП, "Волгадорстрой" ҖЧҖ, "Нурдорстрой" ҖЧҖ, "Восток" ЦТО ҖЧҖ, "ДД" ҖЧҖ, "ЗВКС" АҖ |
| 12. | Күпкатлы торак йортларда (эвакуация баскычлары, балконнарда ябык люклар | 10.10.2015 | Җирлекләр башлыклары, ТКХ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ачкычлары булу) янгынга каршы саклау системаларының торышын, подвал һәм чормалы биналарын ягулык чүп-чарыннан чистарту эшләрен тикшерү, шулай ук ябык люкларны, чорма ишекләрен һәм подвалларны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | | департаменты, «Жилкомплекс» ИК, идарәче компанияләр (килешү буенча - "ТР буенча ФПСның 8 отряды" ФПХИ янгын сүндерү частьлары вәкилләре, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча идарәсенең ЗМР буенча ОНД, Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре) |
| 13. | Билгесез яшәү урыны булмаган затлар яшәү өчен хуҗасыз корылмаларда һәм башка урыннарда янгыннарны профилактикалау буенча кирәкле эшләр башкару. | 10.10.2015 | Җирлекләр башлыклары, ТКХ департаменты, «Жилкомплекс» ИК, идарәче компанияләр |
| 14. | Зеленодольск муниципаль районы территориясендә янгынга каршы тышкы су белән тәэмин ителешне тикшерү чаралары | 10.10.2015 | «ТР буенча 8 ФПС отряды» ФДУП |
| 15. | Юл юлларының машина юлларында, ишегалды юлларында, автотранспортны кую мөмкинлеге булган башка урыннарда урнашкан янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итү чыганакларында автотранспорт чараларын туктатуны тыя торган тиешле күрсәткечләр урнаштыру эшләрен башкару, шул ук вакытта янгын техникасын су белән тәэмин итү чыганакларына кертү чикләнә. | 10.10.2015 | АЖ башлыклары, ТКХ департаменты, "Жилкомплекс" ИК, идарәче компанияләр |
| 16. | Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы оешмаларында, предприятиеләрендә һәм учреждениеләрендә, авыл җирлекләрендә - гражданнар җыеннарында - көзге-кышкы янгын куркынычы чорының үзенчәлеген исәпкә алып янгын куркынычсызлыгы һәм янгын чыгу очрагында гамәлләр кылу чараларының үтәлеше турында инструктаж үткәрү. | 10.10.2015 | Җирлек, поселок башлыклары, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, предприятие, оешма җитәкчеләре (килешү буенча - "ТР буенча ФПСның 8 отряды" ФПХИ янгын сүндерү частьлары вәкилләре, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | идарәсенең ЗМР буенча ОНД, Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре) |
| 17. | Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы халкына көзге-кышкы янгын куркынычы чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары турында хәбәр итү. | Даими | «Татмедиа» ААҖ, «Зеленый Дол» мәгълүмат үзәге, «Зеленодольская правда», «Наш Зеленый Дол», «Яшел Үзән» газеталары редакцияләре. «ТР буенча ФПСның 8 отряды» ФДУП матбугат хезмәте |
| 18. | Кешеләр күпләп була торган урыннарда (эре сәүдә үзәкләрендә, базарларда, вокзалларда һ.б.) янгын куркынычсызлыгы турындагы текстларны трансляцияләүне тәэмин итү. | Даими | «укыла торган юллар» булган оешма җитәкчеләре |
| 19. | Гражданнарны яшәү урыны буенча янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүне оештыру, халык арасында көзге-кышкы янгын куркынычы чорында янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәү турында агитация һәм пропаганда материаллары әзерләү һәм тарату. | 15.10.2015 | АҖ башлыклары, ТКХ департаменты, "Жилкомплекс" ИК, идарәче компанияләр |
| 20. | 2015-2016 елгы көзге-кышкы янгын куркынычы чорында торак пунктларны файдалануга әзерләү өчен яшәү (электр, җылылык һәм су белән тәэмин итү) объектларын һәм торак пунктларны әзерләү максатыннан янгын-профилактика чаралары комплексын үткәрү. | 10.10.2015 | Зеленодольск муниципаль районының инфраструктур үсеш һәм төзелеш департаменты, ЗМР ТКХ департаменты |
| 21. | Комиссия тикшерүен оештыру һәм яңа ел чаралары уздырылачак биналарны кабул итү (аларның янгынга каршы таләпләргә туры килүе предметы). | 2015 елның 12 декабреннән 29 декабренә кадәр | Җирлек башлыклары, мәгариф идарәсе башлыклары, Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, Мәдәният идарәсе, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләре (килешү буенча - "ТР буенча ФПСның 8 отряды" ФПХИ янгын сүндерү частьлары вәкилләре, Россия |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча идарәсенең ЗМР буенча ОНД, Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре) |
| 22. | Яңа ел каникуллары чорында кулланылмый торган муниципаль предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр биналарын комиссияләр тикшерүен оештыру. Янгын автоматикасы системаларының эшкә сәләтлелеге биналарында тикшерү. Планлы эшләрне башкаруга бәйле булмаган персоналны объектлар- ларга кертүне чикләү. | 2015 елның 12 декабреннән 29 декабренә кадәр | Җирлек башлыклары, мәгариф идарәсе башлыклары, Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, Мәдәният идарәсе, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләре. |
| 23. | Кешеләр күп була торган объектларда Яңа ел чаралары уздырганда җаваплы вазыйфаи затларның кизү торуын оештыру.<br>Янгын чыккан, янгын сүндерү чаралары кулланылган очракта, объектларның дежур һәм эш итүче персоналы белән практик гамәлләрен эшкәртү. | .<br>2015 елның 12 декабреннән 29 декабренә кадәр | Җирлек башлыклары, мәгариф идарәсе башлыклары, Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, Мәдәният идарәсе, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләре. |
| 24. | Мәгариф учреждениеләрендәге стендларда янгынга каршы күрсәтмә агитация урнаштыруны оештыру. Укучыларга пиротехник эшләнмәләрдән файдалану кагыйдәләрен һәм Яңа ел чаралары вакытында янгын куркынычсызлыгы чараларын аңлату. | 26.12.2015 | Мәгариф идарәсе башлыгы<br>«ТР буенча 8 ФПС отряды» ФДУП |
| 25. | пиротехника әйберләрен саклау һәм сату шартлары буенча билгеләнгән таләпләрне тулысынча үтәү максатында базарларны һәм сәүдә предприятиеләрен тикшерү буенча рейдлар уздыруны оештыру. | 01.12.2015 - 26.01.2016 | Кулланучылар базарын үстерү бүлеге, ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ЗМР буенча идарәсе башлыгы, (килешү буенча - ФГКУ «ТР буенча 8 ФПС отряды» янгын сүндерү частьлары вәкилләре, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | идарәсенең ЗМР буенча ОНД, Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре) |